**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Карабаш шәһәр тибындагы поселогы составына керүче Иркен авылы торак пунктында гражданнар җыены**

**05.12.2022 ел, № 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы шәһәр тибындагы Карабаш муниципаль берәмлеге составына керүче Иркен авылында гражданнар җыены

Карар итте:

2023 нче елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге составына керүче Иркен авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннары, армия хезмәтенең хәрби хезмәткәрләре,мобилизациягә чакырылганнарның гаилә әгъзаларыннан,суд карары буенча эшкә яраксыз дип танылган яисә ирektән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, гражданнарның үзара салымын 1000 сум күләмендә кертергә.

Җыелган акчаларны Иркен авылы җәяүлеләр юлларын һәм тротуарларны төзекләндерүгә һәм ремонтлауга юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
«Карабаш шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы ___________ И. И. Җәләев